ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.11.2020 № 886

Нурлат муниципаль районы буенча яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен 2020 елның IV кварталына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының нормативын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 1710 номерлы карарын, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2020 елның IV кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 557/пр боерыгын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы буенча яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2020 елның дүртенче кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясенең нормативын 53 919 (илле өч мең тугыз йөз унтугыз) сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин